Тукай муниципал районы Калмия авыл җирлеге Калмия авылы

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«28» ноябрь, 2021 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Калмия авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2022 елда яшәү урыны буенча Калмия авыл җирлеге Калмия авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (бишйөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле ) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

1. Калмия авылы территориясенә балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.

2. Калмия авылы территориясендэге спорт мәйданчынына коймалар сатып алу һәм урнаштыру.

3.Калмия авылы территориясендәге спорт мәйданчыгын каплау өчен җайланма (сатып алу һәм урнаштыру)

2. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Калмия авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3.Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Калмия авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Калмия авыл җирлеге Башлыгы Р. Ә.Гарипов